**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» март 2019 ел № 78

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының муниципаль бюджет мәдәният учреждениясе "Әтнә туган якны өйрәнү музее" уставына (яңа редакция) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы көрәш турында" Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы уставы белән карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының 2013 елның 19 мартындагы 105 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының муниципаль бюджет мәдәният учреждениясе "Әтнә туган якны өйрәнү музее" уставына (яңа редакция) , түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 11 бүлек өстәргә:

"11 бүлек. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу".

Мәнфәгатьләр каршылыгы астында учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы аларның хезмәт бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясарга мөмкин һәм учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм учреждение хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләре арасында каршылык барлыкка килергә мөмкин булган хәл аңлашыла.

Учреждение хезмәткәренең хезмәт бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынуы дигәндә, акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән милек хокуклары, яки үзе өчен яки өченче затлар өчен мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтү рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

Учреждение җитәкчесе гамәлгә куючыга вазыйфаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш, ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала.

Учреждение хезмәткәре учреждение җитәкчесенә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш, ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала. Учреждение җитәкчесенә хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәне теркәү тәртибе учреждение җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

2. Бүлек һәм пунктларның нумерациясен үзгәртергә:

11 бүлек "Башка нигезләмәләр" дип 12 бүлек, ә 11.1, 11.2 пунктлар 12.1, 12.2 пунктлар дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының муниципаль бюджет мәдәният учреждениясе "Әтнә туган якны өйрәнү музее" директорына вәкаләтле органда гамәлгә кую документларында үзгәрешләр һәм өстәмәләр дәүләт теркәве буенча вәкаләтләр бирергә.

4. Әтнә район башкарма комитетының 2011 елның 14 декабрендәге 800 номерлы карарының 2 пункты һәм Әтнә район башкарма комитетының 23.10.2009 елдагы 279 номерлы карарының 2 пункты үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әтнә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге начальнигы Р.М.Галләмовага йөкләргә.

Әтнә районының башкарма
комитеты җитәкчесе А.Ф.Каюмов

Татарстан Республикасы Әтнә районы
Башкарма комитетының 2019 елның
"___" __________ номерлы карары белән
расланган.
Әтнә районының башкарма
комитеты җитәкчесе
__________ А.Ф.Каюмов

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының муниципаль бюджет мәдәният учреждениясе "Әтнә туган якны өйрәнү музее" уставына (яңа редакция) үзгәрешләр һәм өстәмәләр (ОГРН 1101690011510, ИНН 1610002829)**

Уставка түбәндәге эчтәлекле 11 бүлек өстәргә:

"11 бүлек. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу".

Мәнфәгатьләр каршылыгы астында учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы аларның хезмәт бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясарга мөмкин һәм учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм учреждение хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләре арасында каршылык барлыкка килергә мөмкин булган хәл аңлашыла.

Учреждение хезмәткәренең хезмәт бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынуы дигәндә, акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән милек хокуклары, яки үзе өчен яки өченче затлар өчен мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтү рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

Учреждение җитәкчесе гамәлгә куючыга вазыйфаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш, ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала.
Учреждение хезмәткәре учреждение җитәкчесенә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш, ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала. Учреждение җитәкчесенә хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәне теркәү тәртибе учреждение җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

2. Бүлек һәм пунктларның нумерациясен үзгәртергә:

11 бүлек "Башка нигезләмәләр" дип 12 бүлек, ә 11.1, 11.2 пунктлар 12.1, 12.2 пунктлар дип санарга.